РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» 11 2018 г. №803

Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
Регламентын раслау һәм Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 елның 14 маеннан булган №316 карарына
үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына таянып, Башкарма комитетның 2011 елның 16 мартындагы«Ютазы районының җирле үзидарә органнары һәм Башкарма комитеты бүлекләре тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы 105 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 маендагы 316 номерлы карарының 1-12 кушымталарының 5.1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә: «3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документлар яисә мәгълүмат, яисә эшләр башкаруны таләп итү;".

3.Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының jutaza.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырырга .

4.Әлеге карарныц үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе вазифаларын башкаручы З. Н. Айтыкина

И.М. Гыйлаҗева

8 (85593) 2-73-07